***Тәхау*** *Касыйм*

# *КЫРМЫСКА УЛЫ КЫРМЫСКАК МАҖАРАЛАРЫ*

Әкият

**Казан**
**Татарстан китап нәшрияты**
**2007**

# *ШУНДЫЙ БЕР ОЯ БАР*

Аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән болын буйлап, боргалана-боргалана, мул сулы елга ага. Ярларында тал һәм зирек агачлары үсеп утыра. Елганың бер борылмасындагы сул як ярыннан урман башлана. Пәһлеван чыршылары, нарат, имән һәм каеннары белән тирә-юньгә билгеле калын урман ул. Аның читендә утырган юан каен төбендә әкәмәт зур кырмыска оясы урнашкан. Ул киң итәкле чүмәләгә охшаган. Оя елдан-ел киңәя, югарыга күтәрелә. Күрәмсең, кырмыскалары тырыш. Биредә ничәмә-ничә миллион кырмыска яши! Хәер, аларны кем санаган да, кем бу хакта баш ваткан. Ә оя, табигать кырыслыкларына бирешмичә, үз көнен үзе күрә бирә.

Оядан төрле тарафка кырмыска юллары сузыла. Шул сукмакларда бөҗәкләр ыгы-зыгысы — берәүләр каядыр ашыга, икенчеләре ил-йортына таба йөгерәләр. Өйләренә кайтучыларның берише кипкән үлән кисәген бергәләшеп өстериләр, калганнары оядашларына азык алып кайталар. Ауга чыккан кырмыскалар, йөк күтәргән иптәшләренә юл биреп, читкә тайпылалар, аннары яңадан алга чабалар. Алар барысы да эшче кырмыскалар. Ояда әле сакчы, төзүче, нәнкә-тәрбияче, башка төрле вазифаларны башкаручы кырмыскалар да бар. Барысы да үз эшен белеп, карусыз һәм төгәл үтиләр.

Мин сезгә бакча, болын, чүл яки тропик урманнарда яшәүче кырмыскалар хакында түгел, әлеге урман читендә, зур каен төбендәге ояда торучы җирән урман кырмыскалары, бигрәк тә кырмыска улы Кырмыскак, аның маҗаралары турында сөйләргә булдым.

# *«МИН — КЫРМЫСКА УЛЫ КЫРМЫСКАК!»*

Кырмыскак май аенда дөньяга килде. Көннәрнең берсендә, җир астыннан чыгып, ул оя башына менеп басты, аннары тирә-якка күз ташлады. Табигатьнең гүзәллегенә хәйран калып, сары, шәмәхә, зәңгәр, ак чәчәкләр белән бизәлгән болынны, урман буен берничә тапкыр күзәтте. Оя төбендәге биек каенга да карап алды, аннары янәшәдә генә үскән тузганакларның алтын-сары чәчәкләренә күз төшерде. Бу мизгелләрдә исә урман эче кошларның моңлы җырлары белән тулган иде. Кырмыскакка дөнья матур, кызык һәм гаҗәеп серле бер нәрсә булып тоелды. Ул, чамадан тыш хискә бирелеп, бар тавышына кычкырып җибәргәнен сизми дә калды:

— Мин үзем яши торган бу җирнең, бу як табигатенең барлык хикмәт-серләрен беләчәкмен. Шушы якның җан ияләре, мин — кырмыска улы Кырмыскак!

Аның сүзләрен беренче булып кырмыска оясы янындагы агачта утырган гөблә — үлән бете ишетте. Аның коты алынды, куркуыннан чак егылып төшмәде.

Бермәл аңына килеп, ул:

— Бу кырмыска минем татлы сөлемне суырып эчеп бетерәчәк, — диде. — Мине «савым сыеры»на әверелдерәчәк, сөлем белән тамагын туендырачак.

Якын-тирәдәге кошлар Кырмыскак тавышын ишеткәннәрдерме-юкмы, белмим. Алар сайрадылар да сайрадылар. Ә менә чикерткә, күршесенең каты аваз салганын ишетеп, черелдәвеннән кинәт туктады.

— Без кырмыскалардан өркә торган җан ияләре түгел, — диде ул. — Сусыл үләне, чәчәкләре кояшка карап

елмайган алан, урман буйлары — безнең биләмәләр. Без үзебезчә яшибез. Телибез икән — черелдәп җырлыйбыз, биисебез килсә — биибез. Кояш җылы нурларын сипкәндә, чәчәкләрдә ял итәбез, күк зәңгәрлегенә карап хозурланабыз.

# *БЕРЕНЧЕ ТАНЫШУЛАР*

Чикерткәләр үз эшләре белән мәшгуль булды. Кырмыскалар да көнне бушка үткәрмәделәр. Алар үзләре салган сукмаклар буйлап төрлесе төрле тарафка ашыктылар. Кырмыскак та, өлкәннәр төркеменә ияреп, юлга чыкты. Карт Баба кырмыска — төркем башлыгы — нәни чыбык кисәген өстерәп кайтып килгән оядашын туктатып, ярдәм итәргә ашыкты.

— Юк, кирәкми. Йөгем әллә ни авыр түгел, — диде яшь эшче кырмыска. — Сез үз эшегездә булыгыз.

Төркем башлыгы иптәшләре артыннан чапты. Алар шактый юл үттеләр. Кырмыскак та башкалардан калышмады.

Бермәл алар инеш ярына килеп җиттеләр. Күпне күргән, төрле хәлләр кичергән тәҗрибәле төркем башлыгы, яр читендә туктап, арткы аякларына басты да әмер бирде:

— Ары юл юк! Шушында ял итәбез дә, ил-йортка кайтканда, оядашларыбыз өчен азык хәстәрлибез. Безнең вазифа — азык запасы туплау.

— Ризык нинди була соң ул, аны кайдан һәм ничек табарга? — диде Кырмыскак.

— Моңа кадәр син өлкәннәр ташыган ризыкны ашап яшәдең, чөнки син бала гына идең, — диде төркем җитәкчесе Баба кырмыска. — Хәзер син, Кырмыскак, үз көнеңне үзең күрәчәксең, иптәшләрең турында да кайгыртачаксың. Сине өлкәннәр барысына да өйрәтерләр.

Кырмыскалар сөзәк ярда озак юанмадылар. Әмма алар шул арада елганың тын суына, су өстендәге төнбоек яфракларына, инеш буйлап очкан яшькелт, ак, күк һәм кызгылт-чуар күбәләкләргә сокланып карап тордылар.

Баба кырмыска, башкалар да белеп торсын дипме, әйтә куйды:

— Елганың бу җирендә су киңәеп, җәелеп ага. Ул шушы төштән икенче юнәлеш ала. Күрәсез, аның култыгы зур булмаган күлне хәтерләтә. Тын сулы урын. Төнбоеклар шундый төшне үз итәләр. Әлегә сез аларның су өстендә тирбәлгән яфракларын гына күрәсез. Тора-бара алар, зур һәм ап-ак чәчәкләре белән көязләнеп, көннәр буе кояшны күзәтерләр, төнгә йомылырлар — йокыга талырлар.

Бабаның шулай бирелеп сөйләгәнен Кырмыскак гаҗәпсенеп һәм кызыксынып тыңлады. Аңарда шушы култыкка көн саен килү, төнбоекларның ак чәчәкләренә карап соклану теләге уянды.

— Бирегә тагын кайчан киләбез? — диде ул Бабага.

— Җәйнең һәр матур көнендә, — дип җавап бирде карт кырмыска.

## *ГӨБЛӘНЕ МЕНӘ ШУЛАЙ «САВАЛАР»*

Кырмыскалар кайтыр юлга чыктылар. Кырмыскак төркем башлыгына иярде. Кырмыскаларның һәркайсы үзе белгән җирдә ризык хәстәрләргә кереште. Ләкин алар бер-берсеннән ерак китмәделәр. Ә Баба сукмак читендә үсеп утырган балан куагына юнәлде, анда барып җиткәч, яшь ботак буйлап өскә үрмәләде. Ботакның яфраклары бик сусыл иде. Гөбләләр баланны сырып алганнар, яфракларын бөтергәннәр. Алар әйтерсең лә куыш эчендә яшиләр. Алай гынамы соң, беркая бармыйча, яфрак суын суыралар — тамак туйдыралар.

— Мин шушы баланда гына гөбләләр үрчетәм, — диде Баба кырмыска. — Аларны «савып», туйганчы татлы сүлләрен эчәм. Шул ризыкны оядашларыма алып кайтам, аларга өләшәм. Кырмыскак, карап тор, гөбләне менә ничек «савалар».

Төркем башлыгы, үлән бетен мыеклары белән кытыклап, аның сүлен бүлдереп чыгарды һәм эчәргә кереште. Аннары икенчесенә барып ябышты.

— Син дә минемчә эшлә, Кырмыскак! — дип, ул өченчесен «сава» башлады.

Кырмыскак та шулай эшләде. Баллы сүлдән аңа хәл кергәндәй булды. Аннары кычкырып болай диде:

— Бигрәк тәмле икән бу сүл! Баба, көн саен шушы агачка килербез, яме!

— Шулай итәрбез. Ә син азыкны күбрәк тупларга тырыш!

Алар, баланнан төшеп, ояга сузылган сукмакка чыктылар. Баба кырмыскага тагын берничә иптәше кушылды. Аларның да корсаклары сүл белән тулган иде.

— Гөбләләрне кайда «саудыгыз»? — дип сорады Баба алардан.

— Безнең «ферма» каен үсентеләренең ботакларында урнашкан, — диде арадан бер кырмыска, янәшәдә утырган агачка ишарә ясап. — Гөбләләрне шунда үрчетәбез.

Ә гөбләләр «савымчылар»га бер ризасызлык та белдермиләр. Шулай булмый ни, кырмыскалар аларны дошманнарыннан саклый бит. Димәк, бу ике якка да отышлы.

Сары кырмыскалар гөбләне оя эчендә, үлән тамырларында үрчетәләр. Шулай итеп, үлән бетләре, көн яктысын күрмичә, гомерләрен җир астында үткәрәләр. Ә кырмыскаларның моңа һич тә исләре китми — аларга үз гөбләләре янәшәдә булсын.

*** * ***

Кайтып җитәр алдыннан Баба юлда шуышкан парсыз ефәк күбәләге кортын очратты. Корт яңа гына оясын ташлап чыккан һәм агач ботагыннан җиргә егылып төшкән, ахрысы. Баба аны эләктереп алды да каты итеп тешләде. Тәне авыртуга түзә алмаган корт боргалана-боргалана сикерә башлады. Аңа Кырмыскак та килеп ябышты, ул аны каты итеп баш артыннан тешләде. Корт,

хәле бетеп, җиргә сузылып ятты. Кырмыскалар аны дәррәү ояга өстерәделәр.

Төркем башлыгы оя янында иптәшләренә тап булды. Ул:

— Нинди ризык тупладыгыз? — диде аларга.

— Без тайтояк һәм миләүшә суын җыйдык, — дип җавап кайтарды тегеләре.

Башка төркем кырмыскалары икенче бер юлдан ауга киткәннәр иде. Аларның да бүгенге көне уңышлы булган икән.

Ханча — ояның хуҗасы, ана кырмыска — барысын да мактап телгә алды:

— Сезнең кебек тырышлар, тәвәккәлләр булганда, безнең оя халкы киләчәктә дә исән-имин яшәр!

# *ГАҖӘП МАНЗАРА*

Үлән болында куе һәм биек булып үсте. Ал һәм зәңгәр, ак һәм шәмәхә чәчәкләр кояш нурларында назланып утыралар. Елганың дымлы яр буйларында һәм суга якын урыннарында бөтнекләр хуш исләрен чәчә. Кая карама, җәйнең илаһи көче, экияти гүзәллеге хөкем сөргән вакыт.

Инешнең күлдәй җәелгән тын култыгында төнбоеклар, кояшка карап, суда җай гына тирбәләләр. Гүя алар, шушы култыкны могҗиза почмагы ясар өчен, елга төбеннән су өстенә күтәрелгәннәр. Су лаләләренең һәрберсе чынаяк асты кадәр. Алардан әйтерсең лә күзләрне камаштыргыч ак нурлар бөркелә.

Инеш ярына ялгызы гына килгән Кырмыскак төнбоекларга озак карап торды. Түзмәде, ярдан су буена төште. Култыкта тамырдан ауган каен кәүсәсе ята иде. Кәүсәнең як-ягына төнбоеклар сибелгән.

Кырмыскак кәүсә буйлап чәчәкләрнең берсенә — агачка терәлеп торган су гөленә юнәлде. Ул шул чәчәктә ял итмәкче

булды. Акрын гына тирбәлгән су киңлегенә күз ташлап хозурлану үзе ни тора!

Кәүсәнең урта өлешенә җитәрәк, кырмыска малае чәчәккә үрмәләде, аннары төнбоек таҗларында арлы-бирле йөгерә башлады. Көтмәгәндә лалә яфрагына бака баласы менеп утырды. Кырмыскакның моңа кәефе кырылды. «Бу акай күзгә биредә нәрсә калган, мине нигә борчып йөри әле ул?» — дигәндәй, шыпырт кына бака баласына таба атлады. Ул аның арткы тәпиен каты итеп тешләде.

Акай күз, авыртуга түзә алмыйча:

— Бака-как! — дип кычкырды. — Әнекәем, мине үтерәләр. Миңа кемдер энә кадады. Коткарыгыз мине! — диде.

Кырмыскак үрле-кырлы сикергән бака баласының корсагын да тешләргә өлгерде.

— Монда мин хуҗа! — дип аваз салды Кырмыскак. — Чәчәккә якын да киләсе булма!

Тегесе, корсагы әрнүенә түзә алмыйча, аркасы белән суга мәтәлде, аннары корсагына әйләнеп, арткы тәпиләре белән этә-этә йөзеп китте.

— Белеп тор, онытма минем кем икәнлегемне. Мин — кырмыска малае Кырмыскак!

# *ХӘВЕФ-ХӘТӘР КӨТМӘГӘНДӘ КИЛӘ*

Кырмыскак янәдән чәчәккә менеп утырды. Як-ягына каранып алды да чалкан ук сузылып ятты. Ул зәңгәр күкне озак күзәтте. Ял иткәннән соң, торып, таҗ читенә килеп басты, аннары күзен суга төбәде. Шул хәлдә хозурланып судагы җан ияләрен күзәтте. Гаҗәп, алар суда да күп икән. Әнә күзгедәй ялтырап торган

култыкта, озын һәм нечкә аякларын чылатмыйча гына, суүлчәр — су атчыгы йөзә. Үзе суда батмый да. Ул кинәт йөзеп китә, бераз бара да шып туктый.

Кырмыскакка бу күренеш кызык булып тоелды. Ул:

— Их, мин дә аның кебек йөзә алсам иде, — дип көрсенеп куйды. — Нигә бу бөҗәктән көнләшәм соң әле, ул, безнең кебек, җирдә йөри белми бит.

Шулчак төнбоек каты итеп селкенеп куйды. Кырмыскак суга карады. Анда чәнечкеле аркалы, иләмсез гәүдәле зур җан иясе күренде. Ул төнбоек сабын селкетә ләбаса! Кырмыска улы шүрләп куйды.

Чуртан иде ул. Куркыныч иде бу зат. Аның авызы иләмсез зур, пычкы тешләр белән тулган. Күзләре бик усал карый. Ул-бу булмагае дип, Кырмыскак чәчәктән суда яткан агачка күчте, кәүсә буйлап ярга таба элдертте. Аннары ярга күтәрелеп, таныш сукмактан оясына атлады. Ул гөбләләр яшәгән баланга да сугылды. Анда корсагы тулганчы гөблә сүлен эчте. Кырмыскак кояш баеганда гына өенә кайтып җитте. Иптәшләре аны күптән көтәләр икән.

Алар бертавыштан:

— Кайда югалып йөрисең? — дип каршыладылар.

Кырмыскакның җавабы кыска булды:

— Елгада булдым, төнбоек чәчәгендә ял иттем, кояшта кызындым. Бака баласын көлкегә калдырдым, — диде ул.

Кырмыскак үзе алып кайткан гөблә сүлен оядашларына эчерде дә йокларга ятты. Көн буена йөргән, усал чуртан белән очрашкан, тәмам талчыккан кырмыска улы шундук изрәп йокыга да китте.

Иртә белән дус-ишләре аның янына җыелдылар.

Арадан берсе:

— Бака баласын ничек кызык иттең, Кырмыскак? — дип сорады.

Кырмыскак түкми-чәчми барысын да сөйләп бирде. Иптәшләре аның кыюлыгына хәйран калдылар, шаккаттылар.

Әмма бер дусты, аңа ышанмыйча:

— Әкияттер бу, — диде. — Болай ук булмас. Арттырып җибәрдең бугай, Кырмыскак.

— Ышанасыңмы-юкмы, анысы синең эш, — диде Кырмыскак һәм үз юлында булды.

## *КЫЧЫТКАН КҮБӘЛӘГЕ*

Кырмыскакны төнбоек башкача кызыксындырмады. Ул икенче көнне таныш булмаган җиргә юл тотты. Оядан унбиш адым чамасы ары киткәч, кырмыска улы ромашкалар үскән урында туктады. Чәчәкләрнең берсендә кычыткан күбәләгенең нектар эчеп утыруын күрде. Аның янына менде дә каршысына ук килеп басты.

— Чәчәктән нәрсә эчәсең? — дип сорады ул.

— Баллы су — нектар суырам.

— Яле, миңа да күрсәт!

— Менә шулай, озын борыным белән эчәм. Җип-җиңел.

— Ә минем борыным юк бит. Синең кебек булдыра алмыйм мин. Миңа да өлеш чыгармассыңмы, күбәләк?

— Алайса, чәчәк таҗына татлы су тамызам. Авыз ит, Кырмыскак!

— Рәхмәт, Чуаркай! — диде кырмыска, кинәнеп. — Тәмле нәрсә икән нектар. Яныңа тагын килсәм, син мине сыйларсыңмы?

— Әйе. Без тагын да очрашырбыз әле! — диде дә Чуаркай урман буйлап очып китте. — Исән бул, Кырмыскак!

— Исәнлек-иминлек сиңа, асыл зат!

# *КҮРШЕЛӘР КАЙГЫСЫН УРТАКЛАШУ*

Вакытында җил исте, вакытында яңгыр яуды. Кояш җир йөзенә җылы һәм назлы нурларын сипте. Җәй шулай тантана итте. Кырмыскалар, шуңа шат булып, кайгы-борчуларсыз, ипле тормыш кичерәләр иде.

Табигатьнең гүзәллегенә таң калып, шөкрана кылып яшәгән бервакытта күрше оя кырмыскаларында кайгылы хәл булды.

Кырмыскак өенә кайтып килә иде. Ул юлда җан биргән кырмыскага тап булды. Аны иснәп карады — ят ис. «Безнең ояныкы түгел бу», — дип уйлады Кырмыскак. Ул аны, аркасына салып, үз ояларына алып кайтып китте. Аның артыннан чит кырмыскалар да иярде.

— Юлда очраттым мин аны, — диде Кырмыскак, кайтып җиткәч. — Күрше оядан булса кирәк.

— Безнең йорттан ул, — диделәр ияреп килгән кырмыскалар. — Ул бездә бик хөрмәтле зат, исеме Кырмыскай иде.

— Кайгыгызны уртаклашабыз, — диде Баба кырмыска. — Дан-хөрмәт белән без аны сезнең ил-йортка илтеп куячакбыз. Тик шунысы гаҗәп: ул безнең biләмәгә ничек килеп эләккән дә ни сәбәпле безнең сукмакта вафат булган?

— Аптырама, Баба. Безнең Кырмыскай бик карт, үз гомерендә күпне кичергән зат иде. Исәрләнеп китеп, ул сезнең юлга эләккәндер, — диде чит кырмыскаларның төркем башлыгы. — Ничек кенә булмасын, Кырмыскай йорт-илебез өчен бөек сәяхәтче булып кала. Ул безнең урманны аркылыга-буйга йөреп чыкты. Аның белмәгән җире юк.

Кырмыскайны күтәреп оясына алып киттеләр. Кырмыскак аны үз аркасында күтәреп барды. Башкалар аның артыннан иярделәр.

Кырмыскайны зурлап җирләделәр. Күрше оя ханчасы мәрхүмне зурлап телгә алды, игелекле эшләре хакында сөйләргә онытмады, башкаларны да аның үрнәгендә яшәргә чакырды.

Ике оя халкы, бер-берсенә рәхмәт белдереп, киләчәктә дә тату яшәргә вәгъдә биреште.

Кырмыскакны «Кырмыскай бөек сәяхәтче иде» дигән сүзләр уйга калдырды. Ул бу хакта ничәмә-ничә көн уйланып йөрде: ни өчен аны «бөек сәяхәтче» дип йөртәләр?..

# *ТУЗГАНАК ҺӘМ ТИКТОРМАС КЫРМЫСКАК*

Тузганаклар орлыклы «парашют»ларын очыра башлады. Җил аларны тирә-якка, әллә кайларга куа иде. Кырмыска оясыннан ерак түгел үсеп утырган ялгыз тузганак та ак йонлы «бүреген» киде. Башкалардан соңарып өлгерде ул. Бер-бер артлы һавага күтәрелгән «парашют»ларны күреп, Кырмыскак тузганак янына килде. Ул алтындай сары чәчәкләре белән елмаеп утырган бу үсемлекне күптән белә. Аның тузганак чәчәгенә менеп ял иткән чаклары да булды. Чәчәк, кояшка карап, җилдә чайкала. Шуңа менеп утырган Кырмыскак үзен бишектә тирбәлгәндәй хис итә иде.

Бу юлы ул бирегә берничә иптәше белән килде. Оядашлары тузганак төбендә басып калдылар, ә ул әлеге «бүреккә» таба үрмәләде. Тәпиләре белән «парашют»ларга тотынуы булды, кинәт искән каты җил аны һавага очырды, каядыр еракка алып китте. Котлары алынган иптәшләре, нишләргә белмичә, баскан җирләрендә үрә катып калдылар. Аңнарына килгәч, ояларына чаптылар.

Кырмыскакның да коты очты, күзләре шардай булды. Җил аны урман буйлап, аннары инешнең югары агымындагы басу өстеннән очырта башлады.

Аста, гәрәбә төскә манчылган иген кырында, комбайн арышны теземнәргә сала. Бу күренеш Кырмыскакка гаҗәп һәм кызык булып тоелды.

Оча торгач, сәяхәтченең күзе яшел болында утлап йөргән сыер көтүенә төште.

— Болары кемнәр соң? — дип үзалдына сөйләнде ул. — Очлы мөгезләре дә бар үзләренең.

Кырмыскак янында очкан бал корты, аның сүзләрен ишетеп:

— Сөт бирә торган йорт хайваннары — сыерлар, — диде.

Кырмыскак бал кортын — Безелдекне күптән белә, аны чәчәкләрдә күп тапкыр очратканы бар.

— Син сәяхәт итәсеңме әллә? — дип сорады Безелдек Кырмыскактан.

— Мине җил тузганак «парашют»ында очыртып алып китте. Хәзер дөнья гизәм. Кызык икән күктән җиргә карап очуы.

— Куркытмыймы соң?

— Башта шүрләгән идем дә, хәзер үземне әйбәт хис итәм. Туган ягым белән күптәннән танышасым килгән иде. Менә хыялым чынга ашты.

— Син, Кырмыскак, кай җиргә барып төшәрсең икән? Югыйсә ояңнан ерак киттең. Йорт-иленә таба юл табарсыңмы?

— Үзем дә шул хакта уйланам. Минем кебек кечкенә затка җирдә үлән арасыннан йөгерә-йөгерә өйгә кайтып җитү мөмкин нәрсә түгелдер.

— Хафаланма, Кырмыскак. Җае чыгар, — дип юатты Безелдек сәяхәтчене.

Бал корты шулай диде дә күздән югалды.

## *НИ ҖИТМИ БУ КИГӘВЕНГӘ?*

Сыер көтүе өстеннән шактый ара очканнан соң, Кырмыскак авылга якынлашты. Ул, бу очышка, сәяхәткә күнегеп китеп, үзен тыныч тотты. Хәтта аның гел очасы, ерак җирләр белән танышасы килде. Ләззәтле уйларга чумып барган бер мәлдә ул якында гына ниндидер безелдәгән тавыш ишетте. Шул арада торна борчагыдай күзле кигәвен пәйда булды. Кырмыскак сискәнеп куйды.

Беренче булып сүзне кигәвен башлады:

— Нәрсә син, кырмыска, һавада очасың әле? Сиңа җир җитмәгәнме әллә? Күк — безнеке, канатлы җан ияләренеке!

Кигәвеннең тавышы тупас һәм усал иде. Сәяхәтче куркуыннан «парашют»ын чак ычкындырып җибәрмәде.

Ул:

— Мин үзем теләп очмыйм, — диде мескен тавыш белән. — Мине җил һавага күтәрде...

Шулчак каршы җил чыгып, сәяхәтчене яңадан таныш кыр өстенә борды. Кигәвен дә Кырмыскактан калышмады. Көтүгә якынлашканда, ул сәяхәтченең баш очында безелдәргә тотынды.

Кигәвен тагын зәһәрен чәчте:

— Мин — көчле, гайрәтле бөҗәк нәселеннән. Мин — ата-бабалар шөгылен дәвам иттерүче. Бездән беркемгә дә шәфкать юк! Син дә миннән яхшылык көтмә!

— Ә кырмыска халкы — урман санитары, — диде сәяхәтче. — Без урманда төрле паразитларга, корткыч кортларга каршы көрәшәбез. Син, мактанчык бөҗәк, көтүгә төшеп, сыерлар арасында яман гадәтеңне күрсәт алайса!

— Ә нигә күрсәтмәскә! Юкка мактанмыйм мин. Күзләреңне тутырып ач та аска кара. Әнә минем биш туганым бөтен көтүне тараткан. Сыерлар әрле-бирле чабыша. Алар кая кереп яшеренергә урын тапмыйлар, койрыкларын чәнчеп йөгерешәләр.

Бу хәлне күреп торган Кырмыскак Безборын сүзләренә тәмам ышанды. Ул кигәвеннәрнең мәкерле, канечкеч җаннар булып яралганнарын үз күзләре белән күрде. Безборын, сәяхәтчене ялгыз калдырып, көтү өстенә уктай атылды. Аның Кырмыскакка үз «һөнәрен» күрсәтәсе килә иде.

Безборын үгезнең аркасына очып төште дә очлы борынын аның тәненә батырды. Үгез авыртуга чыдый алмыйча сыгылып куйды, аннары кинәт алга томырылды һәм шул арада койрык очы белән аркасын суккалый башлады. Билгеле, кигәвен аның калак сөяге турысына, койрык җитмәслек урынга кунган иде. Белә ул малларның кайсы төшеннән кан эчәргә. Бу хәлне күреп, сәяхәтче өнсез кала язды.

— Минем янга тагын килмәсә генә ярар иде бу хәшәрәт, — диде ул.

«Парашют» көтү өстендә очып йөргәннән соң, янә авылга таба юнәлде.

Шул арада әрсез Безборын, Кырмыскакны куып җитеп:

— Күрдеңме мине?! — диде. — Үгезне «Әпипә»гә биеттем. Без ярдәмгә мохтаҗ түгел. Ә менә синең белән нишләргә? Тәнеңә борынымны батырыр идем, син бик кечкенә. Шуңа күрә сиңа карата бер әмәлем бар: канатларым белән бәреп төшерәм мин сине. Авылдагы бер өйнең калай түбәсенә. Шунда дөмегерсең, берәр кошка җим булырсың.

— Син ерткычмыни?

— Без шундыйлардан! Кырмыска, белеп тор кем белән очрашканыңны!

Кигәвен Кырмыскакны «парашют»ыннан ычкындырырга кереште. Ни хикмәт, шул чакны бер кош Безборынны томшыгы белән эләктереп капты да йотып җибәрде.

— Синдәй хәшәрәтләрне һәрвакыт шундый җәза көтә, — диде ул. — Син, Кырмыскак, дошманыңнан азат. Сәяхәтең иминлек белән төгәлләнсен, йорт-иленә кайтып җитәргә насыйп булсын!

— Рәхмәт сиңа, Чебенче! Син мине үлемнән коткардың, — диде кырмыска, шатлыклы тавыш белән.

Әйе, кошның исеме Чебенче иде. Ул ничек тиз килеп чыкса, шулай күздән югалды.

Авыл өстенә җитәрәк «парашют» җил уңае белән инешкә таба очуын дәвам иттерде. Елга ярында колач җитмәслек юан кәүсәле биек тал үсеп утыра иде. Кырмыскак җиргә якынлаша башлады. Җил әкрен искәнгә, тузганак таллардан биеккә күтәрелә алмады. Ниһаять, «парашют» каршыдагы юан талга килеп бәрелде. Сәяхәтче, исән-имин калуына куанып, тәпиләре белән талның тар һәм сары яфрагына ябышты.

Кырмыскак, үткән юлын яхшы хәтерләсә дә, йорт-иленә кайтып җитәренә ышанмады. Чынында бу кечкенә бөҗәк чокыр-чакырлар, иңкүлекләр һәм киң кыр аша туган йортына ничек кайта алсын ди?! Ике чакрым араны тәпиләргә аның гомере дә җитмәс иде.

# *КЫРМЫСКАК «КӨЙМӘ»ДӘ ЙӨЗӘ*

Төш авышканчы Кырмыскак талда ял итте — саргайган яфракта черем итеп алды. Елга аңа көзгедәй ялтырап күренә иде. Сәяхәтче, карашын еракка ташлап, һәр тарафны җентекләп күзәтте. Аның исәбе йорт-иленең кайсы якта урнашканын белү, шул юнәлештә юлга чыгу иде.

Тагын җил күтәрелде. Талдагы сары яфрак кырмыска белән бергә су өстенә очып төште һәм әкрен генә йөзеп китте. Ул кечкенә көймәгә охшаган, ә аңа утырган Кырмыскак көймәчене хәтерләтә иде.

— Тагын ниләр күрәсем бар икән? — дип үзалдына сөйләнде ул.

Менә «көймә»дәге Кырмыскакның баш очында энә карагы күренде. Ул вертолет шикелле канатларын кагып бер урында тирбәлеп торды да болай диде:

— Кай якларга юл тотасың? Көймәдә йөзгән кырмысканы беренче күрүем.

— Сәяхәт итәм. Син белеп тор: мин — кырмыска улы Кырмыскак!

— Сиңа үз ояң тирәсендә яшәү хәерле. Синең йөри торган юлың өегездән елга ярына хәтле генә.

— Әй, энә карагы, Калтырканат, син минем ояны beләсеңмени?

— Ник белмәскә — беләм! Минем биләмәм инешнең башыннан алып син белгән култыкка кадәр. Анда төнбоекларга төшеп, чәчәкләрендә ял итәргә яратам.

— Ә ул култык моннан еракмы?

— Бәлкем, кояш иңгәндә шунда йөзеп барып җитәрсең. Елга — җир түгел ул. Анда төрле хәлләргә юлыгуың ихтимал. Мин суга баткан канатсыз бөҗәкләрне күп күрдем. Менә нәрсә, Кырмыскак, култыкка ерак әле. Алда сине шарлавык көтә. Шуңа күрә ул урында су уртасына кермә. Көймәңдә ярга терәлеп үт. Шарлавык — хәтәр нәрсә.

Кырмыскак пошаманга төште. Әмма, шайтан гына өметсез дигәндәй, сәяхәтченең күңелендә үз иленә кайтып җитү теләге көчле иде. Ә Калтырканат инешнең югарыгы агымына таба юл тотты. Аның күздән югалуы булды, «көймә»гә озынборын төшеп утырды. Сәяхәтчегә күңеллерәк булып китте. Ни дисәң дә, алар хәзер икәү, бер-берсенә дошман да түгелләр.

— Нинди нужа сине көймәдә йөзәргә мәҗбүр итте? — дип сүз башлады озынборын.

— Елга белән танышырга исәпләдем. Дөнья гизү начар эшмени?

Су ияләре «көймә»дә йөзгән бөҗәкләрне тиз күреп алдылар. Маймыч озынборынны чак эләктермәде.

Ул «көймә»нең уртасына килеп утырды да сүзен дәвам итте:

— Кырмыскак, син ярты юлыңны үткәнсең инде. Көн кичке якка авышып бара. Бүген ояңа кайтып җитәреңә ышанмыйм. Сиңа бер тәкъдимем бар. Хәзер елга уртасындагы утрауга якынлашып киләбез. Алтын чәчәкләр утравы дип атала ул. Анда сарыдан-сары чәчәкләр елмаешып утыралар. Алар күбәләк халкын магниттай үзләренә тарта. Билгеле, без дә утрауны үз итәбез. Бәлкем, төнне шунда үткәрерсең?

— Әйбәт тәкъдим, рәхмәт, — диде сәяхәтче. — Төнлә елгада нинди хәл булмас — бәла-казага очравым бар. Алда мине шарлавык көтә.

— Ул әлеге утраудан соң берничә адымда гына. Ярый, мин ары очам. Хәерле юл сиңа, Кырмыскак!

Озынборын һавага күтәрелгәндә, бер маймыч югарыга сикерде, черкине эләктермәкче булды. Ләкин аның бу эше барып чыкмады. Маймыч, нәни дулкынчыклар ясап, кире су эчендә югалды. Боҗралы дулкынчыклар «көймә»не ярга кудылар. «Көймә» ярга килеп терәлде, суга иелеп торган тал ботагына эләкте. Ул тукталып калды. Кырмыскак бу хәлдән котылу әмәлен эзләргә кереште.

# *КӨМЕШ ҮРМӘКҮЧТӘ КУНАКТА*

— Мин моннан үз көчем белән генә котыла алмыйм, миңа ярдәмчеләр эзләргә кирәк, — диде сәяхәтче. — Бәлкем, якынтирәдә үз ишләрем йөри торгандыр.

Кырмыскак тал чыбыгы буйлап ярга чыкты, аннары булышчылар эзләргә кереште. Эзләнә-йөри торгач, ул бер кырмысканы очратты һәм аңа үзенең үтенечен җиткерде:

— Дускай, миңа ярдәм итсәңче. Көймәм тал чыбыгына эләкте. Ил-йортыма юл тота идем. Көтмәгәндә шундый бәлагә тарыдым.

— Кояш баеп бара хәзер. Иптәшләрем ояга юл тотканнардыр. Мин аларны кире борып бирегә чакырыйм әле, — дип, кырмыска алга чапты.

Күп тә үтми, ул, бер төркем иптәшләрен ияртеп, Кырмыскак янына килеп тә җитте.

Алар үзара киңәшләшеп алдылар. Ниһаять, бер сүзгә килеп, орлыкка үскән сарут үләненең нечкә сабагыннан нәни таякчыклар — эттергечләр ясадылар. Кырмыскалар, алар ярдәмендә «көймә»не тал ботагыннан ычкындырып, Кырмыскакны юлга озаттылар.

Кояш урман артына кереп югалды. Ниһаять, сәяхәтчебез утрауга килеп туктады. Ул утрауның гүзәллегенә хәйран калды. Чәчәкләрдән су өстенә алтын-сары нурлар сибелә сыман, гүя гөлләр су өстендә тирбәлә.

Кырмыскак чәчәкләрнең берсендә ял итәргә, төнне шунда үткәрергә исәпләде. Шулчак ул кызыклы бер хәлгә тарыды. Моңа көмеш үрмәкүч — Көмешкәй сәбәпче булды. Ул, сәяхәтчене күреп, аны өендә кунак итәргә, төнне шунда үткәрергә чакырды. Янәсе, су астындагы, елга төбендәге үтә күренмәле оядан Кырмыскакка әлегә билгеле булмаган су асты гүзәллеге белән танышырга һәм хозурланырга була. Сәяхәтче башта Көмешкәйнең тәкъдименә икеләнеп, шөбһәләнеп карады. Ул, бу зат миңа тозак кормыймы икән, дип уйлады.

— Син, Көмешкәй, җирдә дә йөрисең, — диде ул. — Су астында яшәү өчен һава суларга кирәк бит. Ә анда һава юк.

— Һәй, юкка борчыласың, кырмыска! Без мондый тормышның җаен-рәтен бик күптәннән беләбез, һәрнәрсәнең башкалар белмәгән сере бар, Кырмыскак. Без, өскә күтәрелеп, корсактагы сөялләр ярдәмендә һава җыябыз. Тәнебезгә бөрчек-бөрчек һава куыгы ябыша. Куыкчыкларны су астындагы йортыбызга ташыйбыз. Өебезне үзебез эшләп чыгарган матдәдән өреп ясыйбыз. Торагыбыз — әчтерхан чикләвеге зурлыгындагы куык. Эчендә суларга һавасы да җитәрлек. Без су асты дөньясын шуннан күзәтәбез.

— Андый йортта кысан түгелме соң?

— Юк. Анда бик иркен. Әйдә безгә. Кунак итәрмен үзеңне. Безнең тормыш белән дә танышырсың. Курыкма, Кырмыскак, мин сиңа усаллык кылырга һич тә җыенмыйм. Ант итеп әйтәм: алдасам, балык корбаны булыйм.

Сәяхәтчебез Көмешкәй йортында төн чыгарга ризалык бирде.

— Мин су астындагы ояңа ничек төшәргә тиеш соң?

— Хафаланма, Кырмыскак. Син корсагыма тотынырсың. Сине һавалы куыкчык эченә кертермен дә су астына алып төшәрмен. Күз ачып йомганчы өйдә булырбыз.

Көмешкәйнең оясы су төбендә көмеш кебек ялтырый иде. Үрмәкүч сәяхәтчене алдамаган икән: куык-ояның эче һава белән тулган. Кырмыскакка хуҗаның өе ошады. Чыннан да, биредән барысы да күренә.

— Йә, ничек? — дип сорады Көмешкәй.

— Әйбәт. Әнә суүсемнәр җай гына тирбәлә. Балыклар әрле-бирле йөзә.

— Кырмыскак, тамагың ачкандыр. Мин сиңа тиз генә су бете тотып алып керәм. Андый нәрсәдән синең авыз иткәнең юктыр.

Үрмәкүч куык-өй астындагы тишектән чыгып китте. Күп тә үтми, ул килеп тә керде һәм кунагына сый тәкъдим итте. Алар тәмләп кичке ашны ашадылар. Кырмыскак янәдән су ияләрен күзәтте. Бераздан ул йокларга ятты, ничек йоклап киткәнен дә сизми калды. Арыган иде ул. Шуңа, ахры, аңа төнге йокы кыска булып тоелды.

— Безгә өскә күтәрелергә, җиргә аяк басарга вакыт, — дип, сәяхәтче ашык-пошык юлга җыена башлады.

— Безнең Сары чәчәкләр утравы белән дә танышып кит, — диде Көмешкәй үзенең кунагына.

Кырмыскак, өскә күтәрелгәч, андыз сабагы буйлап югарыга, сары чәчәкләргә үрмәләде.

# *ЧУАРКАНАТ ЯРДӘМЕ*

Утрауда иксез-чиксез андыз, сары чәчәк, баллы чәчәк (кыргый җитен), үги ана яфрагы, тузганак, уймак чәчәк, чын йогырт (чыршы үләне), саз кипкәре кебек үсемлекләр елмаеп утыра иде.

Кырмыскак, шушы хозурлыкка хәйран калып, андыз чәчәкләренең берсендә чалкан яткан килеш, тирә-юньне озак күзләде. Әнә, Алтын чәчәкләр утравына ук терәлеп, икенче утраучык урнашкан. Анысын Күбәләкләр утравы дип йөртәләр. Кырмыскак андыздан төште дә үләннәр арасыннан аңа таба атлады. Ләкин ике утрауны бер-берсеннән су аерып тора иде. Шуңа күрә сәяхәтчебез утраучыкка үтә алмады. Аптырап утырганда, Кырмыскак янына Тәвискүз күбәләге төшеп утырды.

— Нигә уйга калдың, кырмыска? — диде ул сәяхәтчегә.

— Утраучыкка чыга алмыйм. Шуңа уйланып утырам.

— Һәй, аптырама! Әйдә аркама мен. Сине җәһәт кенә анда алып чыгармын. Сизми дә калырсың.

— Ярдәмчел икәнсең, Тәвискүз. Рәхмәт сиңа.

Кырмыскак, Күбәләкләр утравы белән танышканнан соң:

— Монда күңелле икән. Чәчәктән чәчәккә күбәләкләр оча-куна йөри. Алар да, күрәмсең, утраучыкны яратканнар, — дип әйтеп куйды.

Утраучык читендә комлык та бар иде. Кырмыскак шунда ятып кояшта кызынырга исәпләде. Ул биредә көнен генә түгел, төнен дә уздырырга каршы түгел иде. Сәяхәтчебез, әле бер ягына, әле икенче ягына ятып, күбәләкләр уенын күзәтте. Алар арасында Кырмыскак күрмәгән-белмәгәннәре дә бар икән. Алар төрле бизәкле, төрле төстәге «күлмәк»ләр кигән. Һәрберсе үз чибәрлеге, үз «күлмәге» белән мактана.

Бермәл бу җан ияләре сары комлыкка очып төштеләр, түгәрәк ясап, әйлән-бәйлән уйный башладылар. Кырмыскакны түгәрәк уртасына чакырдылар. Әнә Тәвискүз, кычыткан, пыялач, тубылгы, адмирал күбәләкләре, чуар, сары, зәңгәр, тагын әллә нинди күбәләкләр комлыкта күңел ачалар. Алар канатларын җилпеп-җилпеп, очып-очып бииләр, аннары, бер-берсенә тотынышып, түгәрәктә әйләнәләр.

Бермәл кычыткан күбәләге Чуарканат түгәрәктән Кырмыскакны читкә чакырып алды:

— Син Кырмыскак бит, —диде. — Башта танымый тордым үзеңне. Бу якларда нишләп йөрүең?

— Сәяхәт итәм. Менә Күбәләкләр утравы ияләре белән таныштым әле.  Монда миңа бик күңелле. Әмма мине хәзер бер нәрсә борчый: ояма исән-имин кайта алырмынмы икән? — дим. Әнә күрәсеңдер, шарлавыкта су ничек шаулап-бөтерелеп ага. Аны көймәдә кичү — минем өчен бик тә хәтәр нәрсә.

— Борчылма, Кырмыскак! Җаен табарбыз. Төнбоеклы култык моннан ерак түгел — ярты чакрым да булмас.

— Сиңа җиңел. Чөнки син — канатлы бөҗәк. Сиңа ерак җирләргә очып-барып кайтуы берни түгел.

— Беләсеңме нәрсә, Кырмыскак, мин сине аркама, ике канат арасына утыртам да җәһәт кенә өеңә алып кайтам.

Чуарканатның бу сүзләреннән сәяхәтченең эченә җылы керде — күңеле күтәрелеп китте.

Әйлән-бәйлән уены тәмамлангач, күбәләкләр төрле якка таралыштылар. Утраучыкта Кырмыскак белән Чуарканат кына калды. Берзаман алар да һавага күтәрелделәр һәм култык ягына очтылар. Шарлавык та артта калды.

Сәяхәтчебез, аска, суга караган килеш, үзалдына сөйләнеп куйды:

— Шарлавык чыннан да инешне иңләп ага икән. Мин мондый киртәне көймәдә йөзеп үтә алмаган булыр идем. Ярый әле дустым Чуарканат бар.

Алда, якында гына ап-ак төнбоек чәчәкләре күренде. Урман да шул: ярга терәлеп диярлек утыра. Култыкка, су өстендә сузылып яткан агачка җиткәндә, Кырмыскак шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Кайтып җиттек бит, Чуарканат! — диде ул.

Куанычыннан дөньясын онытып, сәяхәтчебез, аны-моны абайламыйча, күбәләк аркасыннан суга егылып төште. Чуарканат, бу хәлне тиз сизенеп, Кырмыскак тирәсендә оча башлады. Ләкин соң иде инде. Шуңа карамастан күбәләк

сәяхәтчене күздән югалтмады, канатларын тиз-тиз җилпеп, Кырмыскакның баш очында тирбәлде. Ниһаять, Кырмыскак төнбоекка үрмәләде. Аның хәле мөшкел иде: суда батмас өчен күп көч куйды ул. Аңына килә алмыйча, чәчәктә озак ятты. Янәшәсендә утырган Чуарканат аңа сүз катарга базмады. Шактый вакыт узганнан соң, сәяхәтчебез һушына килде, тирә-юньгә күз атты, аннары ул:

— Мин — батыр зат! Мин — кырмыска улы Кырмыскак! — диде.

— Булган син. Авырлыкларга бирешмәдең. Тәки йорт-илеңә кайтып җиттең, — дип, Чуарканат сәяхәтче белән саубуллашты.

— Елга ярыннан үзем генә дә кайта алам. Рәхмәт сиңа, — дип калды ул, күбәләкне озатып.

# *САРЫ КЫРМЫСКАЛАР БАШКАЧА ЯШИ*

Сәяхәтче төнбоектан агачка чыкты һәм кәүсә буйлап ярга таба ашыкты. Кояш күптән инде урман артына иңгән иде.

Кырмыскак ач иде. Ул төнгә оясына кайтмаска булды. Чөнки арыган иде. Ярда хәл җыеп утырганда, аның янына оядашы килеп чыкты.

— Синме бу, Кырмыскак? — диде ул.

— Мин.

— Синең югалып торуың безне кайгыга салды. Ни генә уйлап бетермәдек без.

— Күрәсең — мин исән. Ерак җирләргә сәяхәт кылдым. Кайтып килешем.

— Әйдә, өебезгә кайтабыз. Тиздән караңгы төшәчәк.

Кырмыскак оядашына «Хәлем бетте, арыдым мин» дип әйтергә кыймады, дөресрәге, аның сер бирәсе килмәде. Ул:

— Син кайт, ә мин биредә калам, — диде. — Иртәгә төш җитәр алдыннан сезнең янда булырмын. Оядашларыма шулай диярсең.

Иптәше ояга ашыкты. Ул күздән югалуга, сәяхәтче каршына сары кырмыска — Сарыкай килеп басты да әйтте:

— Монда ни эш кырып йөрисең, җирән кырмыска? Сиңа өеңә кайтырга вакыт. Җиргә төн караңгылыгы иңә бит.

— Менә уйланып, хыялланып утырам әле. Ерак сәфәрдән соң ял итәргә булдым.

— Алайса, безгә рәхим ит. Бездә кунак булырсың, көч-хәл җыярсың, иртән үз өеңә кайтып китәрсең. Безнең йорт монда гына.

— Мин риза, Сарыкай. Әйдә киттек.

Ояга кергәндә, сары кырмыска иптәшләренә ишетелерлек итеп аваз салды:

— Безгә кунак килде. Күрше оядан. Кырмыскак ул. Батыр һәм кыю зат. Ерак җирләрдән кайтып килеше аның.

Сары кырмыскалар сәяхәтчене олылап каршыладылар. «Ачыккансыңдыр» дип, аңа сый-хөрмәт күрсәттеләр.

— Бу кырмыскалар бүтәнчә яшиләр икән, — дип үзалдына сөйләнде юлчы.

Чыннан да, бу бөҗәкләр җирән урман кырмыскаларына караганда башкача көн күрәләр. Оялары болын үләне арасында, биеклекләре үләннең ярты буена да җитми. Гөбләләрне — «савым сыерлары»н — оя эчендә, үлән тамырларында асрыйлар һәм үрчетәләр. Кирәк чакта аларны «савалар».

Хуҗалар, караңгы төшү белән кунакка урын җәеп, аны йокларга яткырдылар.

Иртә белән Кырмыскак йокысыннан уянып тамак ялгады. Сарыкай аны гөблә сүле белән сыйлады. Сәяхәтче, аларга рәхмәт әйтеп, исәнлек-иминлек теләп, оядан чыкты. Таныш сукмагын эзләп табып, үз йортына юнәлде. Төш җиткәндә кайтып җитте.

# *ХАНЧА ЯНЫНДА*

Кырмыскакның кайсы вакытта өйдә буласын ханчага кичә үк хәбәр иткәннәр икән. Аны зур бер төркем оядашлары каршылады. Алар арасында ханча йомышчысы да бар иде. Кырмыскак оя алдында уйланып басып торганда, йомышчы аңа ханча боерыгын җиткерде:

— Сине ханчабыз үзенә чакыра, хәзер үк!

Шушы хәбәрне ишетү белән, сәяхәтчебезнең башында кырыкмаса-кырык уй бөтерелде. «Хәерлегә генә булсын инде», — дип, ул оя эченә керде, йомышчы артыннан атлады. Алар киң һәм озын коридорлар буйлап үттеләр. Зур зал ишеге каршысына килеп бастылар. Ишекнең ике ягында усал карашлы икешәр сакчы тора иде.

— Безне ханча янына үткәрегез, — диде йомышчы сакчыларга.

Сакчылар йомышчыны яхшы беләләр иде. Шуңа күрә Кырмыскак белән йомышчы бернинди тоткарлыксыз зур залга килеп керделәр. Ханча түрдә — тәхетендә утыра иде. Зал эче яп-якты. Аны тычкан күзе дигән кортлар яктыртып торалар икән. Алар ике як стена буйлап урнашканнар. Кырмыскалар, кайчандыр бу кортларны куаклар арасыннан тотып, саклык белән зур залга күтәреп алып кайтканнар, аларны махсус урыннарга урнаштырганнар.

Әнә ханча тәхетенең уң һәм сул ягында да ике сакчы басып тора. Кулларында очлы сөңгеләр. Ханча башындагы таҗ ут яктысында җем-җем килеп ялтырый.

Кырмыскакның моңа кадәр ханчаны күргәне юк иде. Шуңа күрә ул аңа гаҗәпсенеп, ниндидер могҗизага тап булгандай сәерсенеп карады. Аның йөзе кырыс иде. «Ханчаның миңа ачуы чыккан, ахры», — дип уйлады сәяхәтче. Ул шүрләп куйды. Шундый уйлар халәтендә Кырмыскак Илбикә ханча каршына килеп башын иде, билен бөкте.

— Минем ханлыкта теләсә кем теләсә ничек йөри алмый, — диде Илбикә кырыс тавыш белән. — Һәркемнең үз вазифасы,

үз эше бар. Бездә барысы да мин таләп иткәнчә, мин боерганча хәл ителә. Аңладыңмы, Кырмыскак?

— Әйе, ханчабыз, — дип, Кырмыскак башын тагын да түбәнрәк иде. — Ләкин минем гаебем юк.

— Һәрнәрсәнең, һәр гамәлнең сәбәбе була. Бу хакта миңа ничек аңлатыр идең?

— Сезгә, ханчабызга, түбәнчелек белән башымны иеп шуны әйтә алам: тузганакның йонлач ак башында утырганда, көчле җил кубып, минем белән бергә аның «парашют»ларын һавага чөйде. Барысы да шуннан башланды...

Ул үзе белән булган хәлләрнең барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде.

— Мин сиңа ышанам, — диде Илбикә ханча. — Бу турыда миңа җиткергәннәр иде. Соңгы сүзем шул: иртәгә йорт-илебездә зур бәйрәм була. Кырмыскак, сине тантанага чакырам. Әзерләнеп тор!

Сәяхәтчебез болай буласын көтмәгән иде. Ул, ханчага озын гомер, исәнлек-саулык теләп, зур залдан кече залга чыкты.

# *ЙОРТ-ИЛДӘ БӘЙРӘМ*

Йорт-илдә иртәгә буласы бәйрәмгә бүгеннән үк әзерләнә башладылар. Оядан ерак түгел комлыкны — мәйданны — анда-монда үскән үләннәрдән чистарту эшенә керештеләр. Мәйдан читендә кардай ап-ак ике төп ромашка трибуна хезмәтен үтәргә тиеш. Шуңа күрә аңа таба тигез юл суздылар. Мәйданда парад та үткәрү каралган иде.

Ханча күрше оялардан да кунаклар чакырырга боерык бирде. Илбикә йомышчылары иртүк күрше ояларга чаптылар, тантанага килергә чакырдылар. Ниһаять, кичкә барысы да әзер булды.

Төн якынлашканда, ханча үзенең министрларын һәм киңәшчеләрен чакыртты. Аның, алар белән киңәшләшеп, бик тә мөһим мәсьәләне хәл итәсе бар иде.

Илбикә киңәшмәне ачып болай диде:

— Минемчә, йорт-илебезнең чирек гасырлык юбилеена әзерлек төгәлләнеп килә. Шулаймы?

Министрлар һәм киңәшчеләр бертавыштан:

— Әйе, шулай, ханчабыз! — диделәр.

— Мин сезгә ышанам. Теге яки бу мәсьәләдә кечкенә генә кимчелек килеп чыкса да, җаваплы министрны гафу итмәячәкмен!

Киңәшмәдә икенче мәсьәлә дә каралды. Анысы да илкүләм мөһим мәсьәлә иде. Сакчы гаскәри көчләрнең яңа министрын билгеләү җитди нәрсә булганлыктан, залда утыручылар тирән уйга калдылар.

Моннан бер атна элек сакчы гаскәри көчләр министры Кырмыскабаш вафат булган иде. Картлык чиреннән үлде. Министр йорт-илнең гаскәри көчләрен тиешле хәрби әзерлектә — югары дәрәҗәдә тотты. Ханча аның җитәкчелегеннән канәгать иде.

Залдагы тынлыкны Илбикә бозды. Ул:

— Бу урынга мин Кырмыскакны тәкъдим итәм. Сыналган, кыю һәм батыр оядашыбыз ул, — диде. — Йә, сез моңа ничек карыйсыз?

— Кырмыскакның батырлыгы, акыллы зат булуы хакында без кичә ишеттек, — диде ханчаның беренче киңәшчесе. — Мин бу урынга аны лаеклы дип саныйм.

Министрлар һәм башка киңәшчеләр дә ханчаның тәкъдимен хупладылар.

— Алайса, — диде Илбикә, — иртәгә тантана вакытында минем фәрман ил-йортыбызга һәм кунакларга җиткереләчәк. Аны беренче ярдәмчем укыячак. Шуның белән киңәшмә тәмам.

* * *

Көн матур булып туды. Бәйрәм иртәсендә, йорт-илне сәламләп, күккә кояш күтәрелде. Елмая-елмая, җылы һәм назлы нурларын җиргә сипте. Оя кырмыскалары тантана буласы мәйданга ашыктылар. Ә сакчы кырмыскаларның бер өлеше, ояны уратып алып, үз хезмәтләрен үтәргә кереште. Икенче өлеше хәрби парадка җыенды.

Тантана башланыр алдыннан Илбикә һәм аны уратып алган сакчылар күренде. Ханчаның алтын таҗында кояш нурлары уйный. Кәнизәкләрнең алкаларындагы асылташлары төрле төсләр белән җем-җем киләләр. Сакчыларның күзләре, тирә-якта берәр хәтәр нәрсә юкмы дигәндәй, һәр тарафны айкыйлар.

Ниһаять, Илбикә ак ромашкага — трибунага күтәрелеп, җыелган кырмыска халкына күз ташлады. Кунаклар да трибуна янәшәсендәге озын эскәмияләргә утырдылар. Олы тантанага төкле урман, кечкенә урман, көрән урман, кара бакча, болын, сары җир, кәс, сазлык кырмыскаларының кызыл, агач тишүче кызыл күкрәкле, агач тишүче кара һәм кара башлы кырмыскаларның вәкилләре килгән иде.

Тантананың башлануын белдереп, Илбикә нотык сөйләде:

— Бүген йорт-илебезгә 25 ел тулды. Ул бәйсез зур илләрнең берсе булып тора. Олы бәйрәм көнендә халкыбызның телгә алырдай матур эшләре күп. Ул киләчәктә дә сынатмас дип өметләнәм. Безнең ыруг башкаларга яу белән бармады һәм бармаячак. Без ыруглар арасында һәрвакыт иминлек һәм татулык телибез!

Аның нотыгы кыска булды. Икенче ромашкага министрлар һәм ханчаның киңәшчеләре утырган иде. Илбикә, карашын шул якка төбәп, әмерен җиткерде:

— Баш киңәшче, йорт-ил халкыма фәрманымны игълан ит.

Баш киңәшче, фәрман кәгазен кулына алып, барысына да ишетерлек итеп укый башлады:

— «Мин сакчы гаскәри көчләр министры итеп Кырмыскакны билгелим. Ул йорт-илебезнең ышанычын аклар дип ышанам! *Илбикә ханча*».

Кырмыскакка икенче ромашкага-трибунага менәргә боердылар. Баш киңәшче аңа ант итәргә кушты.

— Мин, кырмыска улы Кырмыскак, ханчабыз Илбикәгә һәм халкыма тугрылыклы булырга ант итәм! — диде гаскәрләрнең яңа башлыгы.

Олы бәйрәм тантанасы хәрби парад белән дәвам итте. Беренче гаскәри колонна алдына Кырмыскак килеп басты. Сөңгеләр белән коралланган тәүге колонна трибуна каршыннан төгәл, ныклы һәм бердәм адымнар белән үтте. Ара калдырып, аның артыннан башкалары узды.

Хәрби парад бетүгә, мәйданга эшче кырмыскалар, төзүче, нәнкә-тәрбияче, разведчик һәм башка кырмыскалар чыкты.

Бәйрәм төштән соң гына төгәлләнде. Башка ыру кырмыскалары кичке якта гына ояларына кайтып киттеләр.


Литературно-художественное издание

Для детей младшего и среднего школьного возраста

***Тахау*** *Касым*
***(Тахаутдинов*** *Касым Нуриевич)*

*ПРИКЛЮЧЕНИЯ КЫРМЫСКАКА*

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

***Тәхау*** *Касыйм*

***(Тәхаутдинов*** *Касыйм Нури улы)*

*КЫРМЫСКА УЛЫ КЫРМЫСКАК МАҖАРАЛАРЫ*

Мөхәррире *Л.М.Шәех*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.09.2007.
Форматы 60г90 $^1/_8$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,0. Шартлы буяу-оттиск 26,0.
Нәшер-хисап табагы 4,44. Тиражы 2000 д. Заказ С-1138.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.